«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында»Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 16 октябрендәге 73 номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) тәртибе һәм аларны оештыру турында нигезләмәгә таянып карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә, ә атап әйткәндә, түбәндәге адрес буенча урнашкан 16:08:150202:530 кадастр номерлы 1001 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында,түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Каратун авыл җирлеге, Морзалар авылы, Северная урамы - Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Каратун авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1.3) «автомобильләр ремонтлау».
2.

2.Гавами тыңлауларны оештыручы составын-оештыру комитетын расларга:

1)Хәсәнов Айрат Мансур улы – Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;

2)Нурмиева Әминә Виктор кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;

3)Исмәгыйлев Радик Салихҗан улы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге башлыгы, бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты;

4)Шакирова Эльмира Фирдүс кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы;

5)Сибгатуллина Гөлнара Мөсәлим кызы – Апас муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе.

3.Гавами тыңлауларны оештыручыга-оештыру комитетына гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4.Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 8 ноябреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары Хантимеров Ленар Тәлгать улына йөкләргә.

Башлык А.Г. Җиһаншин